**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

« 1 » март 2021 с. Тюлячи № 82

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең 2021 елга хакын билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча 2021 елның беренче яртыеллыгына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның 1 кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1779327 сум.

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2264598 сум.

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2911626 сум.

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3882168 сум.

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4852710 сум.

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5823252 сум.

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 6793794 сум.

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 7764336 сум.

1.2. Исәп-хисап нигезендә гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме (1 номерлы кушымта) тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 31127,86 сум.

1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 19808,64 сум.

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 16978,83 сум.

2.2. Җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«01» 03 2021 № 82
карарына кушымта

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының 2021 елга иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы

1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

биредә:

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясе (2021 елның беренче кварталына – 53 919 сум):

а) ялгыз яшәүче граждан өчен: СЖ = 53 919 х 33 = 1779327 сум;

б) ике кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 42 = 2264598 сум;

в) өч кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 3 = 2911626 сум;

г) дүрт кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 4 = 3882168 сум;

д) биш кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 5 = 4852710 сум;

е) алты кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 6 = 5823252 сум;

ж) җиде кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 7 = 6793794 сум;

3) сигез кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 8 = 7764336 сум.

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең иң чик күрсәткече:

$$ПД = 0,7 \times СЖ \times ПС / (1 - (1 + ПС)^{-КП}) / (0,3 \times РС),$$

биредә:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем Шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече;

ПС - бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма); (Россия Федерациясе Үзәк банкы ставкасы елына 4,25%, ягъни аена 4,25/100/12 = 0,0035);

КП - бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча 2021 елның беренче яртыеллыгына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның 1 кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 53 919 сум күләмендә билгеләнгән.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү**

1 номерлы таблица

| 12 | СЖ-торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП)(сум.) | РС-гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ- 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум.) | ПС-кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән чагыштырмасы | ПД-максималь керем (сум) (бер кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 53 919 | 4,25/100/12=0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 1779327 | 1 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 31127,86 |
| 42 | 2264598 | 2 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 19808,64 |
| 54 | 2911626 | 3 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 16978,83 |
| 72 | 3882168 | 4 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 16978,83 |
| 90 | 4852710 | 5 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 16978,83 |
| 108 | 5823252 | 6 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 16978,83 |
| 126 | 6793794 | 7 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 16978,83 |
| 144 | 7764336 | 8 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,3 | 16978,83 |